**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге составына керүче Шәрбән авылы**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**2019 елның 27 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Шәрбән торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР** итте:

1. 2020 елда Аксубай муниципаль районының Шәрбән авыл җирлеге Шәрбән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

**1. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына һәм җирлек торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:**

- Шәрбән авылы Беренче май, Кыр, Пролетар, Крылов урамнары юлларын а түшәү өчен вак таш сатып алу.
- Шәрбән авылы Беренче май, Кыр, Пролетар, Крылов урамнары юлларын тигезләү, грунтлау, ком һәм вак таш түшәү.

3. Әлеге карарны Шәрбән авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган рәсми сайтында: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм **http://pravo.tatarstan.ru/** Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

Аксубай муниципаль районы
Шәрбән авыл җирлеге башлыгы Д.Ә.Шәрифуллин